КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 август г.Казань № 572

Татарстан Республикасында югары квалификацияле кадрлар әзерләүне тәэмин итү турында

Эшче һөнәрләрне популярлаштыру, югары квалификацияле кадрлар әзерләүне тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасында сәнәгать үсешен кадрлар белән тәэмин итүнең төбәк стандартын гамәлгә кертү кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Яшь профессионаллар (Ворлдскиллс Россия)» һөнәри берләшмәләр һәм эшче кадрлар үстерү агентлыгы» берлегенең һөнәри белем бирүче оешмаларны тәмамлаучыларның компетенцияләрен бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыруның нәтиҗәле механизмы сыйфатында Ворлдскиллс стандартлары буенча күрсәтмә имтиханны (алга таба – күрсәтмә имтихан) гамәлгә кертү турында тәкъдименә теләктәшлек белдерергә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын күрсәтмә имтиханны гамәлгә кертү координаторы итеп билгеләргә.

3. Карарга теркәлгән 2017 елда күрсәтмә имтихан үткәрү өчен компетенцияләр һәм һөнәри белем бирүче оешмалар исемлеген расларга.

4. Күрсәтмә имтиханны гамәлгә кертү кысаларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

һөнәри белем бирүче оешмаларны тәмамлаучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясе формасы буларак күрсәтмә имтиханны этаплап гамәлгә кертү буенча «юл картасын» эшләргә;

һөнәри белем бирүче оешмалар бюджеттан тыш эшчәнлекләреннән алынган акча кысаларында әлеге карар белән расланган компетенцияләр һәм һөнәри белем бирүче оешмалар исемлеге нигезендә 2017 елда күрсәтмә имтихан үткәрүне оештырырга;

2017/2018 уку елында күрсәтмә имтихан үткәрү өчен Татарстан Республикасының һөнәри белем бирүче оешмаларның әзерлегенә анализ үткәрүне тәэмин итәргә;

2017 елның 1 октябренә кадәр катнашучылар турында (республика ресурс үзәкләре арасыннан һөнәр белем бирүче оешмалар) тәкъдимнәр һәм 2017/2018 уку елында күрсәтмә имтихан үткәрү графигын әзерләргә;

«Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма белән бергә күрсәтмә имтихан үткәрү өчен экспертлар әзерләү буенча системалы эшне дәвам итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә дәүләт йомгаклау аттестациясе күрсәтмә имтихан формасында узачак һөнәри белем бирүче оешмаларның чыгарылыш укучылары еллык санын исәпкә алып, киләсе 3 ел өчен (2018 елдан башлап) күрсәтмә имтихан үткәрү өчен кирәкле өстәмә акчаның фаразланган күләмен билгеләргә.

6. Үз карамакларында һөнәри белем бирүче оешмалар булган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына 2018 елдан башлап чыгарылыш укучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен Ворлдскиллс компетенцияләренә туры килә торган квалификацияләр бирү күздә тоткан урта һөнәри белемнең барлык белем бирү программалары буенча Ворлдскиллс стандартларын исәпкә алган республика күрсәтмә имтиханы формасында үткәрүне башлап җибәрергә.

7. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Татарстан Республикасы икътисадының реаль секторы предприятиеләре арасында Ворлдскиллс стандартлары буенча тармак чемпионатларын Татарстан Республикасында үткәрүне гомуми координацияләүне гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары, «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән бергә 2017 елның 30 августына кадәр Ворлдскиллс стандартлары буенча тармак чемпионатларын оештыру кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләре эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү өчен ведомствоара эшче төркем оештырырга.

8. «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына 2017 елның 30 августына 2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы икътисадының реаль секторы предприятиеләре арасында Ворлдскиллс стандартлары буенча тармак чемпионатларын үткәрү турында тәкъдимнәр кертергә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 15 август, 572 нче
карары белән расланды

2017 елда күрсәтмә имтихан үткәрү өчен
компетенцияләр һәм һөнәри белем бирүче оешмалар
исемлеге

| Т/с | Һөнәри белем бирүче оешма исеме | Компетенцияләр исеме |
|---|---|---|
| 1. | «Төбәкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Бизнес өчен программалар |
| 2. | | Веб-дизайн |
| 3. | | Челтәр һәм системалы администрацияләү |
| 4. | | Мәгълүмат кабельләре челтәрләре |
| 5. | «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Плиткә белән каплау |
| 6. | «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Эретеп ябыштыру техноло-гияләре |
| 7. | «П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Авиация техникасына хезмәт күрсәтү |
| 8. | «Халыкара сервис көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Пешекче эше |
| 9. | «Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | Лабораториядә химик анализ |

_______________________________________